Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

16.03.2026

Менделеевск ш.

№ 174

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә
түләү буенча бердәм тариф челтәре
кагылмый торган бюджет өлкәсенең
аерым оешмалары хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 нчы номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында" 2018 елның 30 мартындагы 195 нче номерлы карары нигезендә һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсенең Менделеевск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә аңа бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәткә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладу күләме 1,1 мәртәбә индексацияләнә һәм аны 16 928 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo. tatarstan.ru “Норматив документлар" бүлегендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Искаков